**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.04.2016 Балык Бистәсе штп. № 46пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Әтиләр советы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 февралендәге ВШ-12-31 номерлы «Татарстан Республикасында Әтиләр Советы эшен активлаштыру турында» гы мәсьәлә буенча киңәшмә беркетмәсен үтәү йөзеннән карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Әтиләр советын төзергә.

2.Расларга:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Әтиләр советы турында нигезләмәне;
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Әтиләр советы составын;
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Әтиләр советының 2016 елга эш планын.

3. "Авыл офыклары" («Сельские горизонты») район газетасы редакциясенә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Әтиләр советы эшчәнлеге турында мәгълүмат бастырырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Д.Ә.Низамов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 2016 елның 7
апрелендәге 46 пи номерлы
карары белән расланган

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Әтиләр советы турында нигезләмә

## I.Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Әтиләр советы (алга таба-Совет) - ата-аналар җәмәгатьчелегенең дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән социаль-тәрбия тирәлеген яхшырту, балалар, яшүсмерләр һәм гаиләләрне җәлеп итеп профилактик, агарту, спорт һәм мәдәни-үстерү эшен оештыру, хәрби-патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирүне активлаштыру максатыннан оештырылган коллегиаль, даими эшләүче киңәшмә-консультатив орган.

1.2.Совет үз эшчәнлегендә Бала хокуклары турында конвенциягә, Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына, әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3.Совет үз эшчәнлеген хәбәрдарлык, бәйсезлек, законлылык принципларына таянып, иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

1.4.Совет үз эшендә бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау өлкәсендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары, муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре, шулай ук оештыру-хокук рәвешләренә бәйсез рәвештә учреждениеләр һәм оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

## II.Советның төп максатлары һәм бурычлары

2.1.Совет эшчәнлегенең максаты-этиләрнең гаилә өчен статусын һәм җаваплылыгын арттыру, балаларны тәрбияләү, гаилә институтын ныгыту, рухи-әхлакый традицияләрне һәм гаилә мөнәсәбәтләрен яңарту һәм саклап калу.

2.2.Совет бурычлары:

2.2.1.бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау;

2.2.2.гаилә институтын һәм гаилә кыйммәтләрен ныгыту, балаларны тәрбияләү өчен ата-аналарның җаваплылыгын арттыру, гаиләләр белән профилактик эш оештыру;

2.2.3. ир-атларны балалар һәм яшүсмерләр арасында сукбайлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау эшенә тарту;

2.2.4. балалар һәм яшүсмерләргә рухи, әхлакый, мәдәни, физик, хезмәт һәм патриотик тәрбия бирү буенча ата-аналар җәмәгатьчелегенең педагогик потенциалын көчәйтү, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;

2.2.5 балаларны җәмгыять тормышына җайлаштыру һәм социаль ярдәм күрсәтү, девиант тәртибе булган яшүсмерләр белән эшне оештыру;

2.2.6.белем бирү оешмаларына тәрбия процессын оештыруда һәм идарә итүдә ярдәм күрсәтү;

2.2.7.башка социаль институтлар, иҗтимагый оешмалар белән халыкта ата-аналар бурычларын үтәүгә җаваплы караш формалаштыру буенча хезмәттәшлек;

2.2.8. җәмгыятьтә гражданлык татулыгына, тотрыклылыкка һәм тынычлыкка ирешү.

**3. Совет компетенциясе**

3.1 Совет үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен хокуклы:

- гаиләгә, аналарга, атага һәм балачакка ярдәм итүгә юнәлдерелгән максатчан программалар һәм башка хокукый актлар проектларын эшләүдә катнашу;

- юридик һәм физик затлардан үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алу ;

- каралучы мәсьәләләр компетенциясендә булган белгечләрне, экспертларны үз эшләренә җәлеп итү ;

- Совет компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча чараларда катнашу;

- гамәлдәге законнар нигезендә башка чараларны гамәлгә ашырырга.

**4. Советның эшен оештыру тәртибе**

4.1 Совет иҗтимагый башлангычта эшләүче Совет рәисеннән, урынбасарыннан һәм әгъзаларыннан тора.

4.2 Совет эшчәнлеге белән Совет рәисе җитәкчелек итә.

4.3 совет составына балаларның әти-әниләре (законлы вәкилләре) керә.

4.4 Совет утырышы беркетмәсе утырыш секретаре тарафыннан алып барыла.

4.5 Совет карары беркетмә рәсмиләштерелә, сәркатип тарафыннан имзалана һәм Совет рәисе тарафыннан раслана. Совет карарлары тәкъдим итү характерына ия.

4.6 Совет утырышы кирәк булган саен, әмма елына кимендә дүрт тапкыр үткәрелә. Совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы. Утырыш нәтиҗәләре буенча Совет утырышларда катнашкан әгъзаларның гади күпчелек тавышы белән карар кабул итә.

4.7 Совет үз эшчәнлеген Совет утырышында ел саен кабул ителә һәм аның рәисе тарафыннан раслана торган эш планы нигезендә гамәлгә ашыра.

4.8 план чараларының үтәлешен Совет рәисе контрольдә тота. Совет тарафыннан үткәрелә торган планлы чараларның нәтиҗәләре беркетмә, белешмәләр, хезмәт язмалары рәвешендә рәсмиләштерелә.

4.9 совет утырышлары беркетмәләре, аның эшчәнлеген регламентлаучы башка документлар рәис карамагында саклана.

4.10 совет эшчәнлеген туктату аның әгъзаларының гади күпчелеге инициативасы белән, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәҗбүри хәбәре белән гамәлгә ашырыла.

4.11. Совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»муниципаль казна учреждениесе башкара.

апрелендәге 46 пи номерлы
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**
**Әтиләр советы составы**

| | |
|---|---|
| Совет рәисе: | |
| Садиков<br>Ильсур Мансур улы | «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»муниципаль казна учреждениесе башлыгы |
| Совет рәисе урынбасары: | |
| Фатыйхов<br>Минневазыйх Хаҗип улы | «Авыл офыклары» ("Сельские горизонты") район газетасы баш мөхәррире , Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы (килешү буенча) |
| Совет сәркатибе: | |
| Мөхәммәтшин<br>Рөстәм Әхмәтхан улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Трой Урай төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Совет әгъзалары: | |
| Ибраһимов<br>Ильнур Галим улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Мәннанов<br>Мансур Гомәр улы | «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге»муниципаль казна учреждениесе башлыгы |
| Шакиров<br>Илгизәр Альбирт улы | "Балык Бистәсе муниципаль районындагы балалар һәм яшүсмерләр өчен «Акчарлак "социаль приюты" дәүләт казна учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Төхватуллин<br>Васил  Йосыф улы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Балык Бистәсе муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе, " Балык Бистәсе агротехника техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Сәлахиев<br>Накиф Юныс улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы " Котлы Бөкәш урта гомуми белем бирү мәктәбе " муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе директоры |
| Валиев<br>Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Токранов<br>Валерий Георгиевич | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы сәркатибе |

| | |
|---|---|
| Хабибуллин<br>Ленар Рафаэл улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең УУП һәм ПДН бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Ненастьев<br>Евгений Александрович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Форпост" җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәп) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры |
| Сафин<br>Айрат Тәлгат улы | «Балык Бистәсе агрохимсервис» ААҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Китаев<br>Мансур Рафагат улы | «Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе»ДАССОның баш табибы (килешү буенча) |
| Каримуллин<br>Ильшат Ильдус улы | «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге филиалының Балык Бистәсе җирле бүлекчәсе белгече (килешү буенча) |
| Хисаметдинов<br>Рамазан Равил улы | Җирле мөселман дини оешмасы Имам-мөхтәсибе– Балык Бистәсе авылы мәхәлләсе (килешү буенча) |
| Габитов<br>Азат Мөдәррис улы | Рус Православие чиркәвенең Казан Епархиясе (Мәскәү патриархаты) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы Балык Бистәсе авылы Казан Мәрьям Ана иконасы хөрмәтенә чиркәү мәхәлләсенең җирле православие дини оешмасы рәисе, рәисе (килешү буенча) |